Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАР

«07» август, 2025 ел №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге халкының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогын бетерү мәсьәләсен тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставына, Байлангар авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган (Байлангар авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 сентябрендәге 24 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә таянып

## КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.
2. Билгеләргә:
   2.1. гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты – 2025 елның 20 августы, 18.00 сәгатьтә;
   2.3. үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Байлангар авылы, Совет ур., 6 йорт (Байлангар авылы Мәдәният йорты бинасы);
   2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирелә торган адрес: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Байлангар авылы, Совет ур., 6 йорт ( эш көннәрендә – 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр)

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен, түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Кәримуллин Илнар Фәрид улы – Байлангар авыл җирлеге башлыгы;

Шамсутдинов Габделнур Мулланур улы – Байлангар авыл җирлеге Советы депутаты;

Каримуллина Резеда Рифат кызы – Байлангар авыл җирлеге Советы депутаты.

4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында гавами тыңлауларда катнашучылардан язма рәвештә яисә телдән, авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм адресы күрсәтелеп, язма формада 2025 елның 8 августыннан 19 августына кадәр Байлангар авыл башкарма комитеты адресына кабул ителә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Байлангар авылы, Совет ур., 6 йорт.

5. Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Байлангар авыл җирлеге» составына керә торган Сазтамак тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү мәсьәләсе буенча Байлангар авылы, Сазтамак авылы, нормабаш авылы халкы катнашында билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Байлангар авылы,Совет ур., 6, Сазтамак авылы, Ленин ур., 34а, Нормабаш авылы, Вахитов ур., 31 торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына, шулай ук «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Кәримуллин